ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2021 № 1069

Проект документларын, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топографик планны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон формада, дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла торган, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән, социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Проект документларын, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топографик планны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Проект документларын, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топографик планны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 19 маендагы 605 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов